# Мәктәп хәбәрчесе

**№2 (№15) февраль 2020 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе газите*



**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**


## 23 февраль – Ватанны саклаучылар көне




Ватанны саклаучылар көне – иңнәренә погон таккан хәрбиләрнең генә түгел, «Ил», «Ватан», «Бурыч» дигән сүзләргә битараф булмаган һәрбарчабызның бәйрәме. Ватанга һәм халыкка хезмәт итү – үз илен ихлас сөюче гражданнарның һәрвакыт төп максаты булды һәм шулай булып калачак та.



Хөрмәтле ир-атлар һәм армия сафларын тулыландырырга әзерләнүче укучыларыбыз! Барыгызны да Ватанны саклаучылар көне белән котлыйбыз! Сезгә һәм гаиләләрегезгә тыныч күк йөзе, нык сәламәтлек, уңышлар һәм иртәгесе көнгә ышаныч телибез! Ил барда — егет хур булмас, диләр. Сезгә һәрвакыт ихтыяр көче, гаилә бәхете юлдаш булсын! Тормыш сынауларына бирешмичә, һәрвакытта да чын ирләр булып калуыгызны телибез! Укучы малайларыбыз ил сагында торучы кыю, курку белмәс егетләр булып үсәрләр, якыннарының тормышы өчен җаваплылык хисен югалтмаслар дип ышанабыз.

***Барча хатын-кызлар исеменнән "Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе***

## IX сыйныфта мөстәкыйль йомгаклау проекты – нәрсә ул? */Укытучы сүзе/*

Проект эшчәнлеге мәгариф өлкәсенә генә түгел, ә һәр кешенең көндәлек тормышына да кертелгән. Проект нәрсә ул? Гомумән, "проект" ның берничә төшенчәсе бар. Мәсәлән, уникаль продуктлар яки нәтиҗәләр ясауга юнәлтелгән вакытлыча предприятие. Төп сүз – "вакытлыча", ягъни проектның башы һәм ахыры бар. Кайбер билгеләмәләр проектның бу вакыйгага багышланган аерым кешеләр төркеме тарафыннан башкарылуын күрсәтә. Нинди генә билгеләмә алсаң да, булган вакыйгаларның бары тик проект булуын ачыклый алырлык билгеләре бар.

Проект – ул русча "биш П": ПРОБЛЕМА – ПЛАН – ПОДГОТОВКА – ПРОДУКТ – ПРЕЗЕНТАЦИЯ.

Проектның алтынчы "П" – аның ПОРТФОЛИОсы, ягъни проектның барлык эш материалларын үз эченә алган папка, шул исәптән проектлар, планнар, докладлар һ.б.

2нче буын ФГОС мәктәптә проектлау һәм тикшеренү эшчәнлеген мәҗбүри үткәрүне күздә тота. Төп норматив документлар (ООП ООО һәм планлаштырылган нәтиҗәләрне бәяләү системасы турындагы регламент) йомгаклау нәтиҗәләре узенчәлекләрен билгели. Болар – барлык фәннәрдә дә контроль эш; индивидуаль проектны тормышка ашыру; дәүләт йомгаклау сертификатына (БДИ) тапшырылган эш өчен класслар. Шуңа күрә IX сыйныфны тәмамлаучы һәр укучы соңгы проектны язарга һәм якларга тиеш. Әлеге эшчәнлек мәктәп билгеләгән шартларда укучыларының конференциясе формасында үткәрелә.

Проект эшчәнлегенә таләпләр:

1. Проект эшчәнлеге тикшерү, нәтиҗәле эшчәнлек, консультацияләр аша оештырылу.
2. Шәхси йомгаклау проектын үтәү һәркем өчен мәҗбүри.
3. Шәхси проектлар әзерләү барышында укучыларның эшчәнлеге тикшерелә.
4. Проект индивидуаль булырга, яки берничә кешелек төркемнән торырга мөмкин.
5. Проектның җитәкчесе – фән укытучысы, сыйныф җитәкчесе, өстәмә белем бирү педагогы була ала.
6. Проект предметара юнәлештә булырга мөмкин.
7. Тикшеренү һәм проект эшчәнлеген уңышлы гамәлгә ашыру өчен укучылар түбәндәге гамәлләрне үтәргә тиеш:
   - проблеманы дөрес сайларга һәм аның актуальлеген дәлилләргә;
   - гипотезаны формалаштырырга, киләчәк эшчәнлегенең асылын ачарга;
   - эшчәнлекне планлаштырырга, эшчәнлек ысулларын сайларга;
   - тикшеренүләр белән мәҗбүри этаплап контроль, нәтиҗәләр ясарга;
   - алынган теманың практик әһәмиятен ассызыклый белергә.
8. Укучылар проект темасын һәм проект җитәкчесен үзләре сайлыйлар.
9. Балаларның проект эшчәнлеге барышын җитәкче контрольдә тота.
10. Шәхси проектлар буенча эшләрне контрольдә тоту һәм оештыру мәктәп җитәкчелеге боерыгы белән раслана.

Чыгарылыш укучылары, эти-әниләр, югарыда аңлатып үтелгән бу этап җитди карап әзерләнүне таләп итә. Янәшәгездә җитәкчегез булганда, сезнең тырышлык белән уңышлы тапшырырсыз дип калабыз.

***Руфия Гафиятуллина, чит тел һәм биология укытучысы***



### ТНВ бездә кунакта

Быелгысы ел авылыбыз һәм мәктәбебез өчен очрашуларга бай булды дисәк тә ялгышмабыз. Ел башыннан журналистлар төркеме белән җылы аралашулар булды. Инде менә 10нчы февраль көнне мәктәпкә һәм авылыбыз мәчетенә **«Татарстан - Яңа Гасыр»** каналыннан **"Нәсыйхәт"** тапшыруы алып баручысы Ләйсирә Фазлыеваның иҗат төркеме килде. Бу тапшыру авыл җирлеге, мәктәп, мәчет бергәлеген, аларның бергә эшли белү тәҗрибәсен күрсәтте. Тапшыру дин белән кызыксынучыларны гына түгел, ә аны яшәү рәвеше иткән кешеләрнең кечкенә генә җирлектә дә күбәюен исбатларлык мисаллар төшерде. Эшне вакытын бүлә белеп эшләгәндә, ничә төрле булса да, бер-берсенә комачауламавын; авыл өчен, мәктәп, мәчет өчен вакытын да, көчен дә кызганмаган хөрмәткә лаек җитәкчебез Насыйров Рафик Гомәр улы мисалында ачыклап бирделәр.

### Әфган сугышын искә алу



15нче февраль – Совет гаскәрләрен Әфганстан җиреннән чыгарылган көн. Бу дата ел саен мәктәптә сыйныф сәгатьләрендә билгеләп үтелә. Быел бу вакыйганы Иске Әдәм авылы китапханәчесе Тагирова Равия апа башлангычлар өчен ачык чара итеп билгеләп үтте. Балаларның инде күптән яратып өлгергән Равия апалары тематик сыйныф сәгатен гади һәм аңлаешлы итеп уздырды. Ә урта һәм югары сыйныфлар өчен һәр сыйныф җитәкчесе презентацияле чара үткәрде.




### Районда үткән чаралар

21нче февральдә билгеләп үтелә торган Туган телләр көне уңаеннан һәр елны төрле чаралар уздырыла. Быел да район мәгариф бүлеге үткәргән "Туган тел" конкурсында укучыларыбыз Гафиятуллин Фаил (III сыйныф), Гафиятуллин Самат (VI сыйныф) сәнгатьле сөйләм номинациясендә катнашып, III урыннарны яуладылар. (Җитәкчеләре Хәйруллина Рузилә, Гафиятуллина Фәнүзә)

Шулай ук февраль аенда район мәктәптән тыш эшләр буенча үзәк үткәргән "Тылсымлы куллар" конкурсында рәсем буенча Сафеева Настя – I, Донсков Артур – II урынга лаек булдылар. Хәйруллин Айназ "Оныклар Җиңү шатлыгы белән дан тота" конкурсында рәсеме белән – II урынны алуга иреште. (Җитәкчеләре Рузилә Хәйруллина, Альмира Бәширова)

### Көрәшчеләргә бүләк



Барыбызга да билгеле булганча, мәктәптә милли көрәш түгәрәге бик актив һәм уңышлы эшләп килә. Гәзитебезнең узган елгы гыйнвар санында бирелгән интервьюда тренер Илһам абый көрәшү өчен палас кирәклеге турында әйткән иде. Инде менә бу хыял тормышка ашты! Узган җәйдә откан 100 000 сумлык грант акчасына 8×9 м. мәйданлы келәм һәм 40 кг. авырлыктагы манекен мәктәпкә кайтарылды. Әлеге товарлар Петербург шәһәрендәге "Риноспорт" фирмасына заказ биреп эшләтелде. Келәмне Казандагы транспорт терминалыннан мәктәпкә үз машинасы белән 2003 елда мәктәбебезне тәмамлаган Хәсәнов Рөстәм абый кайтарып бирде. Аңа да бу игелекле эше өчен зур рәхмәтебезне белдерәбез. Хәзер инде көрәшче егетләрдән тагын да зуррак җиңүләр көтәсе генә калды.

***Рубриканы Нәзирә Әхмәтова әзерләде. IX сыйныф укучысы***

## Мәктәп хезмәткәре – Бөек Ватан сугышы ветераны

Түбән Майна авылының сугыш ветераннары арасында 1965-1973 елларда мәктәптә завхоз һәм хезмәт укытучысы булып эшләгән Нигъмәтуллин Касыйм абый да бар. Урта һәм өлкән буын кешеләре аны ветераннар белән очрашуларда даими катнашучы, авылның беренче балта остасы булганлыгын яхшы хәтерлиләрдер.

Касыйм бабай 1913 елда Түбән Майна авылында дөньяга килә. Әтиләре, авылда уңганлыгы белән аерылып торган Нигмәтуллин Лотфулла бабай, 1931 елда кулак буларак концлагерьга сөрелә. Аннан кайткач, 1937 елның көзендә “халык дошманы” дип гаепләнеп НКВД палачлары тарафыннан атып үтерелә. Касыйм бабайның сөйләве буенча, ул үзе дә 1941 елның май аенда армиягә алынганчы органнар күзәтүе астында торган.

Бөек Ватан сугышы башланган вакытта Касыйм бабай Көнбатыш Белорусиядә урнашкан 13нче армия составындагы 33нче аерым инжерен-сапер батальонында хезмәт итә. Шул сәбәпле сугышта 1941 елның 23 июненнән үк катнаша башлый. Касыйм бабайның сугышчан биографиясендә Бөек Ватан сугышының барлык күренекле вакыйгалары да искә алына:



- 1941 елның июлендә зур чигенү һәм август аенда Белый шәһәре янындагы оборона сугышлары;
- 1941 елның ноябрендә Мәскәүне саклау - Истра һәм Волоколамск шәһәрләре янындагы оборона сугышлары;
- 1942 елның җәендә Смоленск өлкәсендәге һөҗүм;
- 1942 елның көзендә Сталинград оборонасы һәм контрһөҗүм;
- 1943 елның җәендә Курск дугасындагы сугышлар;
- 1943 елның көзе – 1944 елның язында Украинаны азат итү сугышлары;
- 1944 елның икенче яртысында Польшаны азат итү сугышлары;
- 1945 елда – Германияне яулап алу.

Җиңүне Касыйм бабай госпитальдә каршылый. Сугыш дәвамында ул барлыгы 4 тапкыр яралана. Күрсәткән батырлыклары өчен ул 3 тапкыр “Кызыл Йолдыз” орденына тәкъдим ителеп, шуларның берсен генә алуга ирешә (22.08.1943 е.), (18.09.1943 е.), (07.08.1944 е.). Аңардан тыш тагын “Сталинград оборонасы өчен” (1943 е.), “Батырлык өчен” (31.08.1943 е.), “Сугышчан хезмәтләре өчен” (03.10.1943 е.), “Германияне җиңгән өчен” (06.1945 е.) медальләре белән бүләкләнә.

Сугыштан кайткач та, Касыйм бабай уңганлыгы һәм тырыш хезмәте белән дан казана. Хәзерге вакытта да аның җил тегермәнле йорты авылыбызның күрке булып тора.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***



## Җиңү кайтавазы мәңгелек

Ел саен авыл җирлегенең иҗат-отчет концертлары булып уза. Быел да “***Һәркем өчен бер җиңү***” проекты кысаларында авылыбыз мәдәният йортында “Җиңү кайтавазы мәңгелек” дип исемләнгән театрлаштырылган тамаша куелды. Җиңүнең 75 еллыгына багышланган бу чара хатыннарның ирләрен озату кайгысы, балаларның ятимлек ачысы, авыр хезмәтнең хатын-кызлар, яшүсмерләр өстендә калганлыгы чын-чынлап ышандырырлык итеп күрсәтелде. Тамашада катнашучылар сугыш чорында авылда яшәүчеләрнең авырлыкларны җиңүгә омтылышын, хезмәт батырлыгын бик оста итеп ачып бирә алдылар.

Чарада өлкәннәр белән беррәттән актив катнашкан Әхмәтова Нәзирә, Морадыймов Илназ, Шафиков Әнис, Шәрифуллин Илсафлар сәхнәдә чын артистлар кебек уйнадылар. Залиева Илдеяр белән Мөхәмммәтова Рузилә батыр кызлар ролен башкардылар. Нурматов Халит белән Панов Артур үзләре теләп фронтка китүче егетләр булдылар. Кечкенә Ләйлә сугыш чорында урманга утынга барырга әнисенә ярдәм итүче бала булып уйнады. Гафиятуллин Фаил, Нургалиева Ләйлә, Залиева Вәсиләләр дә, кечкенә булуларына карамастан, үзләренә тапшырган рольләрен җиренә җиткереп башкардылар. Сәхнәнең үзәгендә булган Равия апалар белән бергә, укучылар да халык алдында чыгыш ясау осталыкларын күрсәттеләр. Шулай булмаса тамашачы тын да алмый карап утырмас та иде.

Тамашаны башыннан ахырына чаклы югары дәрәҗәдә әзерләгән, балаларны да сәхнә тормышы белән якыннан таныштыручы, Иске Әдәм җирле үзидарәсе хезмәткәре Морадыймова Гөлнарага олы рәхмәт белдерәбез. Сәхнә киемнәрен тегүче Бәширова Альмира, бию өйрәтүче Сафиуллина Алсу, Хәйруллина Рузилә апаларына да рәхмәтебез зурдан.

***Ата-аналар комитеты исеменнән Энҗе Хоснуллина***


Татарстан Республикасы Президенты

РӘХМӘТ СҮЗЕ

*Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм нәтиҗәле хезмәте өчен*

*Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Түбән Татар Майнасы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры*

*Насыйров Рафикъ Гомәр улына*

*Р.Н. Миңнеханов*

*Казан, Кремль*
*2020 елның 6 феврале*




**/Котлыйбыз!/**

## *Президентның Рәхмәт сүзе*

Мәктәбебез директоры Насыйров Рафик Гомәр улы мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм нәтиҗәле хезмәтләре өчен, һәм 50 яше уңаеннан Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде. Без дә хөрмәтле җитәкчебезне чираттагы уңышы белән чын күңелдән котлыйбыз. Җаваплы эшендә тагын да зуррак нәтиҗәләр, гаилә бәхете, ныклы сәламәтлек, һәм киләчәктә дә авылыбыз өчен олы эшләр башкарып яшәвен теләп калабыз.

## *Туган көннәр*

Хезмәт юлын балаларга математика фәнен өйрәтүгә багышлаган, озак еллар дәвамында мәктәпнең укыту эшләре белән җитәкчелек иткән Хәсәнова Ризидә апаны туган көне белән котлыйбыз. Сәламәтлек белән гаилә иминлеге, озын гомер телибез. Укучыларыгыздан һәрчак рәхмәтләр генә килеп торсын Ризидә апа!

Февраль аенда дөньяга килгән балалар – бакча төркеменнән Камалов Илнурны, I сыйныф укучылары Хәбибрахманов Абдулла белән Донсков Артурны, III сыйныфтан Хусенов Станиславны, IV сыйныф укучылары Нургалиева Ләйлә, Йосыпов Рәсимне туган көннәре белән. Тәртипле, тырыш, һәрвакытта да әти-әниләрен һәм укытучыларын шатландыручы булып үсүләрен телибез.

**/Безнең спорт/**

## *Милли көрәш*



1 февральдә Болгар шәһәрендә уздырылган билбау көрәше буенча ААҖ "Кызыл Шәрык-Агро" призына уздырылган Республика беренчелегендә көрәшче егетбез Камалов Илдус үз авырлыгында I урынны яулады.

8 февральдә Чистай шәһәрендә “Көрәш” балалар фестивалендә Камалов Илдус белән Нурматов Халит үз авырлыкларында I урынны алдылар

23 февраль – Ватанны саклаучылар көне уңаеннан Аксубай район үзәгендә милли көрәш буенча ачык турнирда егетләребез зур җиңүләргә иреште. Үз авырлыкларында Камалов Илдус, Хәбибрахманов Ильяс, Нурматов Халит – I, Хәбибрахманов Әхмәт, Галимов Рияз II урыннарны яулады. Панов Артурны беренче тапкыр җиңүе – III урынны алуы белән котлыйбыз. Барлык категорияләрдә җиңүгә ирешкән егетләргә кубок тапшырылды. Батырларыбызга һәм остазлары Камалов Ильһам абыйга сәламәтлек, уңышлар насыйп булсын.



## *Шахмат ярышлары*

Ир-егетләр бәйрәме булган Ватанны саклаучылар көненә багышланган яллар мәктәбебез шахматчылары өчен көрәш көннәре булып үтте. 24 февраль район мәдәният йортында шахмат буенча район беренчелеге ярышлары узды. Ярышта, яшь һәм әзерлек дәрәҗәсенә бәйсез рәвештә, барлык шахмат яратучылар катнашты. Ярыш бик кызу барды. Нәтиҗәдә, беренче урынны инде өченче тапкыр район чемпионы булган Савелий Купцов алса, икенче урынга Фаил Гафиятуллин, 3 урынга Айназ Хәйруллин лаек булды.

Шахматчыларыбызга киләсе турнирларда да зур уңышлар теләп калабыз.

**<u>Газетаны гамәлгә куючы</u> – Түбән Майна урта мәктәбе**
**<u>Мөхәррир</u> – Фәнүзә Гафиятуллина**
**<u>Редколлегия әгъзалары:</u>**
**Әминә Туктамышева** | **Алия Гыйззәтуллина**
**Виктория Нукина** | **Нәзирә Әхмәтова**
**Зөлфирә Сафиуллина** | **Рузилә Мөхәмматова**
**Сара Насыйрова**